ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

16.11.2022 | с. Коргуза | 04

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнары арасында үзара салым кертүнең беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2022 елның 26 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Үзәк, Пролетарская, Боевая, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

2 этап: Беренче Май, Садовая, Октябрь урамында яшәүчеләр.

3 этап: Заречная, Яр буе урамында яшәүчеләр.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлегенең Карагуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Карагуҗа авылы Боевая урамы, Октябрь урамы юлларына вак таш түшәү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Халык җыеннарын үткәрергә:
   1 этап: Карагуҗа авылы,Үзәк урамда урнашкан кибет яны чатында;
   2 нче этап: Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан урамы буенча мәктәп гаражы янында;
   3 нче этап: Карагуҗа авылы, Яр буе урамы 15 нче йорт янында (Бочков А. И.).
7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов